ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

02.02.2022

№ 84

Алабуга муниципаль районы
Башкарма комитетының кайбер
карарлары үз көчен югалткан
дип тану турында

Муниципаль норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

- «Тәрбияләнүчеләрне стационар хезмәт күрсәтүгә психоневрологик төрдәге интернат-йортларга юнәлтү турында карарлар бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1156 номерлы карары;

- «Суд тәртибендә эшкә яраксыз яисә чикләнгән күләмдә эшкә яраксыз дип танылган балигъ булган зат өстеннән опека яки попечительлек булдыру һәм опекун яки попечитель билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1152 номерлы карары;

-«Үз опекаларындагы затларның мөлкәте белән алыш-биреш ясауга рөхсәт алу буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1169 номерлы карары;

- «Балигъ булмаган бала мәнфәгатьләрендә гомерлек рента килешүе төзүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1157 номерлы карары;

- «Опекунга яисә попечительгә опека карамагындагы затның саклык счетыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1167 номерлы карары;

- «Тәрбияләнүче карамагындагы торакны опекунга наемга бирүгә рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге 1154 номерлы карары;

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов